| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.07.2021 г.Зеленодольск № 79

2020 елның 29 декабрендәге 45 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән расланган, 2021 елга Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планына (программасына) үзгәрешләр кертү турында (2021 елның 24 мартындагы 59 номерлы Карарда кертелгән үзгәрешләр белән)

2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы белән расланган нигезләмә нигезендә , Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тәкъдим иткән 2021 елга Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планына (программасына) үзгәрешләрне карап, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. 2020 елның 29 декабрендәге «2021 елга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) турында» 45 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән (2021 елның 24 мартындагы 59 нче карарында кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, 2021 елга Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планына (программасына) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

«Хосусыйлаштыруга планлаштырыла торган башка мөлкәт исемлеге» таблицасына түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10 | Кадастр номеры 16:49:010206:691 булган 267кв.м мәйданлы торак булмаган бина, кадастр номеры 16:49:010206:33 булган 819 кв.м мәйданлы җир кишәрлеге белән | Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Кызыл тыкрык ур., 3 | 2021 елның III-IV кварталы |

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), сатуларны үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында (http://www.torgi.gov.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы урынбасары** **Э.Р. Кадникова**